ГЛАВА ШЕЛАНГОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Советская, д.7, с. Шеланга,
422577

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ШИЛАНГЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Совет ур., 7 нче йорт, Шиланга авылы,
422577

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

10.10.2023 с. Шеланга 10

Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлегенең Кызыл Байрак поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56нчы ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 28 октябренә Югары Ослан муниципаль районының Шеланга авыл җирлеге Кызыл-Байрак поселогында гражданнардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.
2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2024 елда Югары Ослан муниципаль районының Шеланга авыл җирлеге Кызыл Байрак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Бөек Ватан сугышы ветераннарына һәм тыл хезмәтчәннәренә һәйкәл төзү

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Кызыл Байрак, Үзәк ур., 12 йорт 13.00 сәгатьтә гражданнар җыенын үткәрергә.

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Шеланга авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Шеланга авыл җирлеге башлыгы В. В. Майоров